НИКОЛАЙ СЛАДКОВ

# БАЛЛЫ ЯҢГЫР

## АПРЕЛЬ АЕ



Sabyem.ru



## *Апрель*

Әлегә кадәр кар яткан басу-кырларда уйдык-уйдык җирләр ачыла башлады. Апрель кояшы бүләк иткән сипкелләр дип уйларсың үзләрен.

Басулар көннән-көн чуарлана, сипкелләр торган саен күбәя бара. Озак та үтмәс, көннәрдән бер көнне язгы кар сулары аларны юып язга кушачак.

Озын кыш буена урман-кырлардан гел кар исе генә килеп тора иде. Хәзер исә һәр тарафта ымсындыргыч язгы кар сулары белән бергә сулап туймаслык хуш исләр аңкый башлады. Язның йөгерек җилләре болыннардан җир исен, урманнардан чери башлаган, бурсыган яфрак исләрен алып килә. Яңа шытып чыккан чирәм, ачылып килүче тәүге чәчәкләр исеннән башлар әйләнә. Әле генә йокыларыннан уянган бал кортлары, күбәләкләр, шул хуш исләрне тоеп, чәчәкләргә ашыга. Куяннар яшел үлән татып карау бәхетеннән танауларын җыера. Үзеңнең дә борын шәрифләрең йомшак тал песиләре иснәргә сузыла. Йөгерек урман гөрләвекләре үзләренә мүк исе, былтыргы үлән, бурсыган яфрак, каен суы исләрен сеңдергән. Исләр

көннән-көн төрлеләнә, куера, тәмләнә. Тиздән урман һавасы меңнәрчә исләр букетына әйләнәчәк. Каеннарның сыек томан белән өртелгән ябышкак яфраклары үзләренә генә хас нәфис исләр бөрки.

Шулай итеп, җир өстендәге сипкелләр язга кушылды.

## КЕМ ҖИРЕ?

Көннәрдән бер көнне Саескан кары эри башлаган җирне күреп алды да:

— Тра-та-та, тра-та-та! Җир ачылган икән ләбаса! Тәүге җир, минем җир! Иң башлап үзем күрдем. Минеке! Беркемгә дә бирмим! — дип тирә-юньгә хәбәр салды.

Әлеге җирдә орлыклар күренә, үрмәкүч-коңгызлар мәш килә, лимон күбәләге, янбашын кояшка куеп, кызынып ята. Моны күреп, Саесканның күзләре кызды, авызына сулар килде. Инде шул нигъмәтләрне кабам дип томшыгын сузган иде, Кара карга очып килеп җитте:

— Исәнме-саумы, туганкай! Каян килеп җиттең әле син минем җиргә? Ай-һай иртәләгәнсең. Кеше өлешенә тыкшыну бер дә килешми бит.

—Нишләп синең җир булсын ул? — дип гаҗәпләнде Саескан да үз чиратында.— Иң башлап мин күрдем бит аны.

— Син күргәнсеңдер дә бит,— дип каркылдады Кара карга,— ә мин шушы тәүге җир хакына меңнәрчә чакрымнардан очып кайттым. Җылы якларны калдырып. Шундый кары эрегән җир булмаса, син минем койрыгымны да күрми идең әле. Без, кара каргалар, җир ачылганны дүрт күз белән көтеп торабыз. Минем хакым күбрәк бу җирдә. Минем җир бу.

Тавышка Тургай да килеп җитеште. Боларны күзәтеп, тыңланып торды да сайрап җибәрде:

— Күк аяз, җирдә яз, кояш. Ә сез ду кубып бәхәсләшәсез. Кайда диген әле — минем җирдә!

Саескан белән Кара карга сәерсенеп бер-берсенә караштылар да канатларын җилпеп куйдылар:

— Каян килеп синең җир булсын ул?! Иң беренчесе без таптык бит аны, безнеке ул, борыныңны суза, Тургай,— дип берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә тезеп киттеләр.

— Ә мин, ә мин... шушы җирдә тудым, бик беләсегез килсә! — дип, Тургай түмгәккә кунды да күзләрен кысып, тамагын калтыратып сайрап җибәрде. Тирә-юньгә язгы гөрләвектәй: чең-чең, челтер-челтер җыр агылды. Саескан белән Кара карга авызларын ачып тын калдылар.

Тургайның яз килү шатлыгыннан өздереп-өздереп җырлавын тагын күпме тыңлаган булырлар иде, кисәк кенә аяк астындагы җир селкенеп куйды да балчык арасыннан Сукыр тычкан килеп чыкты. Чыга-чыгышлый ук сөйләнә башлады:

— Әллә кары эреп беткән җиргә туры килдем инде. Чыннан да, туфрагы йоп-йомшак, хуш исләрдән башың әйләнер. Яз исе килә. Яз җиткән икән ләбаса.

— Ямьле яз килде, җир казучы! — дип сөенечен белдерде Саескан.

— Каян чыгарга белгән бу,— дип өнәмичәрәк каркылдады Кара карга.

— Нигә кирәк булды әле сиңа безнең җир? — дип хәвефләнеп сорады Тургай да.

Сукыр тычкан Кара карганы, Саесканны, Тургайны берәм-берәм иснәп чыкты да төчкереп болай диде:

— Бернәрсәгез дә кирәкми миңа сезнең. Җире-

гезнең дә минем өчен бер тиенлек хаҗәте юк. Җир астындагы өнемдә җыелган балчыкны гына өскә ташыйм да кире ояма кереп китәм. Сезнең белән булашып файда юк. Талашасыз, ызгышасыз, сугышырга да күп сорап тормассыз. Җитмәсә, кирәкмәгән якты, коры да икән. Бр-р! Үземнең җир астындагы өнемә җитәме соң?! Үзе караңгы, үзе юеш, дөнья рәхәте. Әле тагын яз җитә, яз дип башны катырасыз...

— Язның ни икәнен беләсеңме соң син? — диде ачуы килеп Тургай.

— Белмим дә, беләсем дә килми. Базымда ел буе бертөрле бит минем.

— Яз көне карлар эреп, җирләр чыга башлый,— диде Саескан.

— Менә шул җирне үзара бүлешә алмыйча интегәбез инде,— дип баягы бәхәсне исенә төшерде Кара карга.

— Нигә бүлешәсез соң аны? Ул җир нәрсәгә кирәк? — дип гаҗәпләнде Сукыр тычкан.

— Бөртекләре бар бит,— дип тырк-тырк сикеренде Саескан.— Яшел чирәмнәр үсеп килә!

— Кирәк икән утырып торасың, кирәк икән йөренәсең, аякларыңны язасың,— дип каркылдады Кара карга.— Томшык белән җирдә актарынасың.

— Җир өстендә сайравы нинди күңелле! — дип һавага күтәрелде Тургай.— Кыр-басуларда кар эреп ачылган җирләрне без көтеп кенә торабыз. Шул чакта гына без сайрый алабыз. Һәркемнең җире үзенә әйбәтрәк тоела.

— Ул җир сезнең барыгызныкы да булгач, ни дип бәхәсләшәсез соң? — диде аңламыйча Сукыр тычкан.— Тургай җир өстендә сайрыйм ди икән, сайрый

бирсен күңеле булганчы. Карга җир өстендә йөрим ди икән, йөрсен рәхәтләнеп.

— Ә Саескан шул арада бөтен орлыкны чүпләп бетерсеңме?! — дип иреннәрен турсайттылар Кара карга белән Тургай.— Дөреслек шул буламы?

— Алайса, башта һәммәгез дә бергәләп ашап алыгыз,— дип киңәш бирде Сукыр тычкан.— Аннан күз күрер.

«Чыннан да, бәхәсләшеп, коры сүз белән тамак туймас, башта ашап алыйк. Аннан карарбыз нишләргә икәнен»,— дип уйладылар кошлар.

Саескан белән Кара карга бөртек-валчыкларны чүпләделәр, Тургай коңгыз, үрмәкүчләрне тотты. Шулай итеп җир өстен ялтыратып, чистартып куйдылар. Тирә-юньгә әйләнеп карасалар, шаккаттылар: алар бәхәсләшкән арада басу өстендә тагын уйдык-уйдык җирләр кардан ачылган. Эскәтер җәеп куйганнармыни?! Ризыкның төрлесеннән рәхим ит, кил дә сыйлан! Кошлар, яз кояшына ияреп, бер җирдән икенчесенә күченделәр. Кызыл балчыкка буялган аяк эзләре оза-та барды үзләрен. Ала-кола кар өстендә кошларның тәүге эзләре иде алар!

## ӨЧӘҮЛӘП БЕР БҮРӘНӘДӘ ЙӨЗҮ

Язгы ташулар вакытында елга, сөзәк ярларыннан ташып, тугайларга, иңкүлекләргә җәелде. Диңгездәй су уртасындагы бәләкәй генә бер утрауда хәйләкәр Төлке белән озын колак Куян бүленеп калды.

— Алдымда су, артымда Төлке, кайларга алып качыйм бу башымны? — дип, Куян мескен утлы табага баскандай утрауның бер башыннан икенче башына атыла да бәрелә.

Көлтә койрык Төлке уйлап торды, торды да Куянга ярдәм кулы сузарга булды:

— Әйдә, Куянкай, сикер минем янга бүрәнәгә. Көпә-көндез карап торып суга батырмам бит инде үзеңне,— диде Төлке кече күңелллеләнеп.

Куянга икеле-микеле уйлап, кыстатып торырга чама юк, утрау күзгә күренеп кечерәйгәннән-кечерәя бара. Төлке янына — бүрәнәгә сикерми нишләсен Куян. Йөзеп киттеләр болар икәүләп елга буйлап, Төлке — бүрәнәнең бер башына, Куян икенче башына утырган.

Боларны Саескан күреп алды да такылдарга тотынды:

— Менә сиңа галәмәт... Төлке белән Куян бер бүрәнәгә менеп чүмәшкәннәр түгелме соң?! Моның ахыры хәерле бетмәс... Бер-бер хәл китереп чыгарырлар болар...

Төлке белән Куян гәпләшә-гәпләшә йөзәләр дә йөзәләр. Саескан яр буйлап бер агачтан икенчесенә күчә-күчә аларны озата бара. Тату гына сәяхәт кылуларына эче поша моның.

Куян, элекке вакытларны исенә төшереп:

— Ташуга чаклы урманда яшь тал ботаклары кимерергә и ярата идем дә соң. Телеңне йотарлык тәмле, сусыл иде алар...

— Әйтмә дә, сөйләмә дә, Куян, кыр тычканнарыннан да затлы ризыкның булганы юк әле. Минем аларны сөяген дә калдырмый бөтен-бөтен килеш йоткан чаклар бар иде,— диде Төлке, матур истәлекләргә бирелеп.

— Әһә,— дип сагайды Саескан.— Әйттем бит, иң кызыгы башлана хәзер!..

Саескан боларның баш очында әйләнгәләп-тулгангалап янган утка май сипте:

— Шып-шыр бүрәнәдә тычканнар каян килсен ди синә, Төлкекәй. Куянны ашамый хәлең юк инде!

Төлкенең ачыгуы җиткән иде, ике дә уйлап тормады, Куянга ташланды. Тик, бүрәнәләре чүлегеп, Куян белән икесе чак кына суга чуммадылар. Төлке ничек итеп кире үз урынына сикергәнен сизми дә калды. Саесканның юри котыртканына ярый әле башы җитте, соң булса да уң булсын дип, тегене пыр туздырып әрләп ташлады:

— Явызның да явызы икәнсең. Урманда гына түгел, су эчендә дә тынгы бирмисең. Койрыкка ябышкан тигәнәк булдың тәмам,— дип и орышты Төлке Саесканны, и орышты.

Саесканның гына исе китмәде, берни дә булмагандай инде Куянны өйрәтә башлады:

— Хәзер инде синең чират, Куян. Каян күргәнең бар Төлке белән Куянның тынышканын? Суга төртеп төшер үзен, мин дә көч бирермен.

Куянга җитә калды, ике күзен чытырдатып йомды да Төлкегә ыргылды. Әмма, бүрәнәләре чүлегеп, тагын суга тәгәри яздылар. Куян яшен ташыдай ялт итеп кенә бүрәнә башына сикерде. Саесканның хәйләсен ниһаять ул да аңлады, ачуланып тетмәсен тетте моның:

— Булса да булыр икән бу кадәр имансыз кош! Безне икебезне тиң үтерәсең килә инде синең, шуңа юри бер-беребезгә каршы котыртасың. Сиздек сереңне, икенчеләй безне төп башына утырта алмассың.

Елга буйлап бүрәнә ага. Куян белән Төлке икесе бүрәнәнең ике башына чүмәшкәннәр дә тату гына гәпләшеп йөзәләр дә йөзәләр.

## ЭЗЛӘР ҺӘМ КОЯШ

Кыш көнендә, Кояш төмсәеп әле офык читендә йөзгәндә, кар өстендәге Эзләргә битараф иде. Кайчакларда гына, кәефе килеп, йөзе ачылып, карларга зәңгәрсу төс иңдерә, ялтыравык энҗеләрен сибештерә иде. Хәзер исә, офыктан югарырак күтәрелгән саен, танып та булмый үзен, тәмам үзгәрде. Эзләрне җебетә, юа, боза башлады.

— Кыш буена урманда булган хәлләрне язып алдык без,— диделәр Эзләр Кояшның һөҗүменә тиз генә бирешергә теләмичә.

— Ә мин ул хәлләрнең бөтенесен юам да бетерәм,— дип гаярьләнде Кояш.

Һәм, кәгазьдәге язуны җуйган күк, эзләрне сөртә башлады.

— Бездә һәр бармак, һәр тырнак эзе калды,— дип үзләрен якламакчы булдылар Эзләр.— Һәркайсы дөрес.

— Дөрес булсани?! — дип бурлаттай кызардыбүртенде Кояш...— Менә хәзер мин бөтенесен бозам, дөресме, ялганмы икәнен үзегез дә аңламассыз.

Шулай дип Кояш Эзләрне җебетте, аркылыга буйга җәелдерде, эретте. Кояш белән Эзләр арасында бәхәс купты. Кем кемне җиңәр, янәсе. Нәкъ җырдагыча.

— Ә без тары чәчтек, тары чәчтек.

— Ә без таптап бетердек, таптап бетердек.

Көн саен эзләр җуела, юыла барды.

Кояш барыбер үзенекен итте.

## КОШЛАР ЗАРЫ

Бу сыерчыклар нинди эш майтарганнар соң ул тиклем?! Яз килдеме, дөнья тутырып сыерчык оялары

элеп куясыз. Алар өлешенә генә тигән нинди бәхет соң бу?! Матур күзле булганнары өченме, әллә яңгыравык тавышлары йә файдалары хакынамы?

Әгәр матур күзле булган өчен шулай кадерләсәгез, ник безгә — карынкыл ябалакларга, соры ябалакларга, йорт ябалакларына куышлар ясап куймыйсыз? Безнең күзләрдән матур күзләр бөтен дөньясында юк. Җем-җем ялтырап торган зур алтынсу күзләр бездә генә.

Әгәр яңгыравык тавышлары өчен хөрмәтләсәгез, нишләп безне — уткойрыкларны, песнәкләрне, чәберчекләрне, чуар чебенчеләрне онытасыз?

Бер дә бүтәнгә түгел, фәкать файдалары өчен генә дисәгез, безгә дә — керәшәләргә, чыелдыкларга, үрмәләчләргә өй ясамыйсыз?

Менә шулай, балалар, колагыгызга киртләп куегыз. Сыерчыкларны гына санлыйсыз бит. Әйтерсең алар гына яңгыратып сайрыйлар, әйтерсең алар гына урманны корткыч бөҗәкләрдән саклыйлар. Без сыерчыкларга каршы түгел анысы, аларны да яратыгыз, тик бүтәннәрне дә онытып бетермәгез.

Без, яз җитү белән, меңнәрчә чакрымнар узып, арып-талып туган җиребезгә кайтып егылабыз.

Әмма, безнең кайтканны гына көтеп торган диярсең, кыш-хаким үзенең холкын күрсәтә башлый. Көннәр салкыная, кар ява, давыл-өермә кузгала. Андый чакларда без кешеләр янына — каралты-кура тирәсенә елышабыз. Кешеләрнең миһербанлыгына ышанганга күрә киләбез.

Ә сез, балалар, шул чакта бездән ярдәмегезне кызганмагыз. Без ипи бөртекләрен, ярмаларны, он кортларын, көнбагышны бик яратып ашыйбыз.

Без дә сезгә бурычлы булып калмабыз. Җәй җиткәч, матур итеп, өздереп, илһамланып сайрарбыз. Без

дигәнем — тургайлар, таң чыпчыклары, чәберчекләр була инде.

## ЯЗГЫ МУНЧА

Моңарчы Галимҗан үзен кошлар хакында мең дә берне беләм дип йөри иде. Аның читлегендә нинди генә кошлар яшәмәде: сары чыпчыклар, чи-чи чыпчыклар, карабүрекләр, песнәкләр, купшыллар, чукырлар, кызылтүшләр һәммәсе кунак булды. Бүген исә Галимҗан мәктәптән кайтышлый мондый хәлгә юлыкты: күлдәвек читендә бөтенләй дә таныш булмаган өч кош кунаклаган, гәүдәләре чыпчыкныкы хәтле булыр. Берсе кара төстә, икенчесе — көрән, өченчесе — җирән. Тырк-тырк сикереп кар суына кереп киттеләр дә болар чупыр-чупыр юынырга тотындылар. Әле түшләрен суга чумдырып-чумдырып алалар, әле артларына чүгеп, шап та шоп канатларын суга кагалар, коеналар. Туйганчы юынгач, күлдәвектән чыктылар да, юеш канатларын кага-кага, комлы сукмакка очып килделәр. Ул да булмады, тәгәрәшеп комда ауный башладылар. Юеш ком канатларына, йон-каурыйларына ябышып, пычранып беттеләр, карарлыклары калмады. Нинди төстә икәнлекләрен дә аермассың.

Комга тәмам батып, оча алмаслык хәлгә килделәр. Тырк-тырк сикеренеп, тагын күлдәвеккә таба киттеләр болар. Янә дә су тамчыларын чәчрәтә-чәчрәтә, тырышып-тырышып юына, чупырдый башладылар.

Бераздан инде чистарынып, аруланып беттек, диделәр бугай, берәм-берәм күлдәвек читенә тезелделәр. Галимҗан кошларны күреп шаккатты. Таныш түгел, билгесез кошлар дип уйлаганы гап-гади чыпчыклар булып чыкты лабаса. Өчесе дә соп-соры, чисталар,

матурлар. Ә күлдәвектәге су болганып, пычранып беткән.

Эшнең нидә икәнен малай шунда гына аңлап алды. Чыпчыклар кыш буена шулай танымаслык булып буялганнар, үзгәргәннәр икән бит. Менә хәзер мунчада юынып, кышкы пычракларыннан арынганнар. Әле җитмәсә, ком белән дә ышкынганнар.

Кара төстәгесе — кыш буена морҗада яшәгәне — корымын юып төшергән.

Көрәне — агач куышында кышлаганы — черек чүбеннән арынган.

Җирәне — стенадагы уентыкка оялаганы — кирпеч тузанын юган.

Менә хәзер чыпчыклар чистаруын чистарганнар, күлдәвектәге су гына кара-көрән-җирән төскә кергән.

— Җиңел пар белән! — дип Галимҗан чыпчыкларны сәламләде дә аяк астындагы кар суларын чәчрәтә-чәчрәтә өенә чапты.

## КАР АСТЫНДАГЫ ЭЗЛӘР

Кыш көннәрендә урманда булган төрле-төрле вакыйгаларны калын кар юрганы каплады. Яхшысы да, яманы да кар көртләре астында калды, бураннарга күмелде. Кем әйтмешли, исе дә, эзе дә юк.

Тик көннәр җылынып, карлар эри башлагач, әлеге яшерелгән хәлләр, шулпа өстендә йөзгән өредәй, берәм-берәм өскә калыкты. Кар өстен ылыс инәләре, эреле-ваклы чыбык-чабыклар, былтыргы бөрешкән яфраклар, агач кайрылары, каен тузлары чуарлады. Тукран тукылдаган агач төпләрендә өем-өем күркә кабыклары эреде.

Кыш ахырында карчыга ботарлаган карганың каурыйлары да күренде. Әнә божырларның, көртлекләр-

нең кар астындагы куыш-ятаклары. Кышның иң зәһәр салкыннарында алар шунда йоклаган иделәр. Менә сукыр тычканның кар асты юлы. Әнә орлыгын чукырлар чүпләгән, калдыгын тиеннәр кимергән күркәләр аунап ята, менә тиеннәр кимергән таллар.

Монысы — ләтчә буып ташлаган җир тычканы. Әнә сусар табыныннан калган очкалак тиен койрыгы.

Гүя китап битләрен берәм-берәм ачып рәсемнәрен карыйсың. Җил белән кояш тиздән ак битләрне бөтенләй бетерәчәк тә катыргы тышлыгы — җир күренәчәк. Һәм шунда кыш көннәрендә булган хәлләр, ничә еллар буе җир өстендә җыелып килгән меңнәрчә эзләр, тамгалар белән кушылып, җиргә сеңәчәк.

## КҮЗАЛДАВЫЧЛАР

Урмандагы искитмәле серле күренешләр гадәттә чит күзләргә күренмичә, сизелмичә үтүчән.

Бүген исә мин, һич тә алданмаска исәпләп, әче таңнан тәлләтәвеч сагалыйм. Борынга төреп тыгардай саф һавалы, тыныч, салкынча таң алды. Урман авызындагы күккә ашкан биек чыршылар күренә. Ә арырак елга аръягындагы тугайлыкларны, елганы томан япмасы каплаган. Куе томанга өртелгән таллар су төбеннән калкып чыккан кара ташларны хәтерләтә. Мин, сихерләнгәндәй, шул талларга карап торам. Әйтерсең ул тарафта ниндидер бер көтелмәгән могҗиза буласы. Тик мин көткән сихрилек һаман юк та юк. Томан йомгаклары иңкүлекләрдән салмак кына елгага таба шуыша.

«Ни хикмәт бу, томан бит өскә күтәрелә торган иде, ә бүген җиргә сылангандай шуыша да шуыша...» дип уйлап куйдым.

Шул мәлне тәллэтәвеч тавышын ишетеп алдым.

Қара төстәге кош, ярканатныкы кебек көчле канатлары белән һаваны сызгыртып, яшькелт күк йөзен ярып бара иде. Мин томанны онытып фотоаппаратыма ябыштым.

Исемә килеп әйләнеп баксам, томан шул арада сыкыга әйләнгән. Аландагы агачлар ап-ак бәскә уралган. Қызганыч, әлеге манзараның ничек булганын күрми калдым. Әллә тәлләтәвеч күземне бәйләде.

Тәлләтәвечләр дә җырлаудан тындылар. Офык читеннән кызарып кояш чыкты. Урмандагы барча җан ияләре тәүге һәм соңгы тапкыр күргәндәй чиктән тыш сөенеп кояшны каршыладылар. Мин дә кояш чыгуын, яңа көн тууын манзара иттем.

Яңадан исемә төшеп аланга күз салсам, исем китте, челтәр-челтәр ап-ак бәс эреп юкка чыккан да күгелҗем сыек томанга әйләнгән. Алтынсу тал песиләре төтен сыман томанга уралган. Бу үзгәрешне мин тагын күрми калганмын!

Урманда гел шулай ул, күз бәйләргә сәбәп табылып кына тора. Иң сихри, иң гаҗәеп күренешләр чит күзләрдән качып-посып кына була да куя.

## СЕРЛЕ АДЫМНАР

Яз башы, кичке эңгер-меңгер вакыт, кара урман эчендәге сазламык. Наратлыкта урыны-урыны белән кар әле эреп тә бетмәгән. Қалку җирдәге чыршылыкта җир инде кибеп килә.

Мин куерып үскән дөм-караңгы чыршылыкка керәм дә каккан казыктай басып торам. Чыршыларның кап-кара кәүсәләре аша баеп баручы кояшның саргылт нурлары төшә. Тирә-юнемдә йөрәк кагышы, тын алуы ишетелерлек серле тынлык. Чыршы башында иренеп кенә миләш чыпчыгы сызгырына. Сызгыра да,

бер-бер җавап ишетмәмме дигәндәй, тыңланып тора, тик тынлыктан гайре аваз-өн юк...

Шул мәлне әкияти тынлыкны ярып кешенекенә охшамаган авыр адымнар ишетелде. Су чупылдавы, боз чылтыравы. Лап-лоп, лап-лоп, лап-лоп! Әйтерсең ат авыр йөген көч-хәлгә сазлыктан сөйрәп бара. Ул да булмады, күк күкрәгәндәй ярсулы үкерү урманны калтыратты, җирләрне селкетте. Авыр алпандай адымнар тынды да, ашыгып-ашыгып, тиз-тиз атлаган адымнар ишетелде. Тыз-быз адымнарга теге авыр адымнарны куып җитү бер дә ансат түгел иде.

Мин аркам белән кәүсәгә сыендым. Болай да эңгер-меңгер булганлыктан, чыршы ешлыгында бигрәк тә караңгы, кәүсәләре арасыннан сазлык әйле-шәйле генә күренә.

Һаваны аркылы-торкылы ярып, теге җәнлек янә үкерде. Тагын җирләр селкенде, урман калтырады. Мин бернәрсә дә уйлап чыгармыйм, чыннан да шулай булды. Тик табигатьнең бу ярсулы, буйсынмас көче курку тудырмый, хөрмәт уята.

Җиңел адымнар топ-топ ашыга-кабалана, су чупылдый, боз чытырдый, мүк шыштырдый.

Мин инде боларның ана аю белән бала аю икәнен күптән аңладым. Баласы җитешми, артка кала, анасының, минем барлыкны сизеп, ачуы килә, бәләкәен ашыктыра, тизләтә. Ана аю үкереп мине кисәтә, янәсе, якын киләсе булма, баласы ялгыз түгел, янында яклаучысы бар. Бик ышандырырлык кисәтә шул, аңламаслык түгел.

Авыр адымнар ишетелми, анасы туктап, бәләкәен көтеп тора. Җиңел адымнар топ-топ килә, ашыга. Менә баласы чыелдап куйды: соңга калма дип, анасы йомшак җиренә берне шапылдатып алды, күрәсең. Аннан соң җиңел адымнар авыр адымнар белән янә-

шә атлап киттеләр: топ-топ-топ, лап-лоп, лап-лоп, лап-лоп! Бераздан әкренәйделәр дә бөтенләй тындылар.

Тагын тынлык.

Миләш чыпчыгы да сызгырмый башлады. Агач кәүсәләренә алка-алка ай яктысы төште.

Җирдәге күлдәвекләрдә йолдызлар кабынды. Әйтерсең һәр күлдәвек — төнге күкнең ачык тәрәзәсе.

Тәрәзәдәге йолдызлар өстеннән атлавы әллә ничек уңайсыз.

Мин ашыкмый гына учагыма таба юнәләм. Йөрәгем рәхәттән кысылып-кысылып куя. Ә колагымда урман хуҗасының гайрәтле, бөек авазы яңгырый.

## ТУЗАН СУЫРТКЫЧ

Ел да була торган хәл инде, быел да бер чыпчык, хуҗалары килгәнче дип, сыерчык оясын алып калырга ашыкты. Кыюлык өчен үзалдына күркәдәй кабарынып, чыркылдап куйды да ояга кереп чумды.

Озак та үтмәде, чыпчык, оя төбендәге иске түшәкне томшыгына кабып, тышка чыгара да башлады. Оя түбәсенә кунып, томшыгын ача да коры салампечәннең аска төшеп китүен карап тора. Зур кауырыйларны берәмтекләп ташый. Алып чыга да җилгә очырып җибәрә. Кауырыйның һава агымы белән йөзеп китүен, йә бөтерелеп аска төшүен күзәтеп тора.

Оядагы бөтен искене чыгарып бетерергә кирәк, чүп-чары да, тузаны да калмасын.

Тузаны да калмасын дип әйтергә генә җиңел. Тузан бөртеген томшыкка кабып та, тырнакка эләктереп тә булмый бит.

Чыпчык оя төбенә түшәлгән каурый, саламның бөртеген дә калдырмады. Тик томшыкка эләкми кал-

ган вак-төяк чүп-чарны, тузанны нишләтергә икән соң?

Чыпчык оя төбәсенә кунды да башын тәпие белән кашып алды. Аннан янә оя авызына кереп чумды. Алга таба ниләр булыр икән дип сабыр гына көтеп торам.

Сыерчык оясында мәхшәр купты. Ярык-тишектән ургылып тузан чыга башлады, зыр-зыр әйләнгән, пыр-пыр кагынган тавышлар килде. Бераздан чыпчык үзе дә күренде. Әзрәк хәл алгандай итте дә яңадан оясына кереп китте. Орчыктай бөтерелеп, тагын тузан очыра башлады. Әйтерсең сыерчык оясы төтенли иде.

Оя эчендә чыпчыкның тузан суырткычы, йә вентиляторы бар микән әллә? Берсе дә юк. Пыр-пыр кагынып, тузынып, чыпчык үзе шулай тузан очыра. Үзе тузан суырткычка әйләнгән.

Менә хәзер инде сыерчык оясы ялт итеп чистарды. Оя төбенә түшәккә дип кипкән печәндер, саламдыр хәстәрләргә дә була. Тик озакка сузмаска, ашыгырга кирәк. Йә ерак-ерак илләрдән ояның чын хуҗасы сыерчык кайтып төшәр.

## СЫЙЛЫ ТАБЫН

Тукран өрәңге агачын без томшыгы белән тиште дә тәмле суын эчте.

Тукранның очып китүе булды, карап кына торган диярсең, озынкойрык песнәк килде дә татлы су белән томшыгын чылатты. Аннан күк песнәк тә озакламады, өч тамчы судан авыз итте.

Кошлар туенгач, инде бөҗәкләргә чират җитте. Көтүе белән чебеннәр ябырылды. Ике кычыткан күбәләге дә алардан калышмады. Тәмлегә талым юк, татлы судан аерып алып булмый үзләрен, ябыштырып

куйгандай, китәргә уйламыйлар да. Мыекларын кыймылдатып, кырмыскалар да килде. Озынборын да читтә калмады, озын тәпиләре белән баллы суга кереп батты.

Бәлки әзер табынга җыелучылар болар белән генә бетмәс тә иде. Тик тәмле суның хуҗасы Тукран килеп җитте. Чакырылмаган кунаклар күз ачып йомганчы юкка чыктылар. Кырмыскага гына котылырга язмаган икән, тукранның озын теленә ябышты да калды. Тукран кунак черкине дә тәмле су белән бергә йотып җибәрде.

Тукран очып киткәч, теге чакырылмаган кунаклар тагын җыела башладылар. Бер-бер артлы озынкойрык песнәк, аннан күк песнәк, алар артыннан чебеннәр, күбәләкләр рәхим итте. Черкиләр, кырмыскалар да ялындырып тормадылар. Чакырганнарын көтеп торыш юк, һәркайсының тәмле судан авыз итәсе килә.

Тәмлегә талым юк, диләр бит.

## АККОШЛАР

Аккошлар гасабиланып башларын чайкыйлар: кеше карап торганга шулай ризасызлык белдерәләр. Болар — диңгез күбегедәй ап-ак, озын, нечкә муенлы, алтынсу томшыклы нәфис аккошлар.

Моңсу, матур тавышлары белән тирә-якны чыңлатып, күктә дә, су, боз өсләрендә дә аккошлар шаугөр килә. Бу шау-шу калган барлык авазларны: кыр үрдәкләренең тиз-тиз канат каккан тавышларын, кыр казларының иренеп кенә каңгылдауларын, тәлләтәвечләрнең моңсу гына сызгырынуларын, тәкәрлекләрнең шатлыклы чәрелдәүләрен күмеп китә.

Берничә аккош томшыкларын кабышып тордылар

да һәммәсе берьюлы, муеннарын өскә сузып, каңгылдый башладылар. Күрәсең, язгы куаныч белән үзләренчә юл хәлләрен сөйләштеләр. Дулкыннар таратып, суны күбекләндереп, ак канатларын шап та шоп суга бәрделәр. Аккошлар биюе иде бу.

Аккошлар язны шулай каршылый. Һәр язны алар кыр үрдәкләре белән бергәләп шушы күлгә төшеп кийл итәләр. Элек тә шулай иде, хәзер дә шулай, киләчәктә дә шулай булсын иде. Соңгы трамвай тукталышларында аккошлар очрый торган шәһәрләрне көндез шәм яндырып эзләсәң дә табып булмый хәзер. Җир йөзендә аккошлар күп калмады.

Бу фани дөньяда аккошлар йөзгән зәңгәр күлләрне нәрсә белән алыштырырга мөмкин? Җәкре көзгеле көлке бүлмәләре алыштырмас бит?

Яр буенда аккошларны күзәтеп сәгатьләр буе утырырга була. Күл өстеннән искән җиләс җил иркәләп биттән сыйпый. Сылу муеннарын сыгылдырып, бер җепкә тезелеп, бозлы су өстеннән аккошлар йөзә. Аккошлар, нәфис муеннарын алга сузып, киң кара тәпиләре белән суны чупылдатып, су өстеннән йөгерәләр, йөгерәләр дә очып өскә күтәреләләр. Аннан ак түшләре белән яшькелт дулкыннарны сөзеп, канатларын очлайтып суга чумалар. Бу матурлыкның сере нидә? Нилектән аккошлардан күзне алмый сәгатьләр буе карап утырырга була? Карашыбыз бер дә бакылдык үрдәкләргә тукталмый бит. Бәләкәйдән алып зурысына хәтле, күзен күккә төбәп: «Карагыз әле, аккошлар оча!» — дип әйттерерлек, күзләр талганчы артларыннан озатып калдырырлык сихри көч бар бу салмак, сыгылмалы, мәгърур кошларда.

# БӨТЕН БЕР ГОМЕР

Язлар җиткәч, ерак юлларны якын итеп, сыерчык оясына әйләнеп кайтты. Әлеге сыерчык минем күптәнге танышым, аягында балдагы бар. Алтынчы елын инде ул мин ясаган ояга кайта.

Менә ул оясын тыштан бик җентекләп тикшерде дә оя эченә кереп кыштыр-мыштыр килә башлады. Бераздан чыкты да оя түбәсенә кунып әкрен генә сайрарга тотынды. Тавышы бик көчле булмаса да, рәвешен китереп җырлый үзе. Әле чәрелди, әле чыелдый, әле сызгыра. Томшыгын өскә чөйгән, күзләрен аларткан, канатларын җәйгән. Әтәч булып кычкыра, бәрәнгә охшатып мәэлди, песи булып мияулый, эт булып өрә. Күрәсең, чит җирләрдә яшәп, ишегалдындагы танышларын бик тә сагынган...

Аннан соң, ана сыерчык белән ояны ялт иттереп чистартып, бала чыгарырлар, бергәләп үстерерләр дә җыйнаулашып урманга очып китәрләр.

...Көз көне җылы якларга очып китәр алдыннан сыерчык урманнан үзе генә әйләнеп кайтты. Сыерчыкларда җылы якларга китәр алдыннан оясы белән хушлашу гадәте бар. Борын астыннан гына нидер көйләп, кояшта җылынып канат-каурыйларын чистартты. Алда — мәшәкатьле, хәвефле озын юл. Алда — зәңгәр офыклар артында чит җирләр.

Яз җиткәч, сыерчыгым тагын әйләнеп кайтыр. Оясында утырып җырлар җырлар, сөенеп канатларын кагыныр.

Менә алты ел инде шулай...

Алтынчы мәртәбә яз җиткәч, мин аның белән исәнләштем, биш тапкыр көз көне саубуллаштым.

Бу юлы сыерчыгымның күзгә күренеп картайганын сиздем.

Әле хәтеремдә, тәүге очрашкан язда ул сайрап туймый иде. Канат-каурыйлары майга манып алгандай елкылдап тора иде.

Инде бу юлы карасам, үз күзләремә үзем ышанмадым. Сыерчыгым бик бетәшкән. Сайравы да сайрау түгел: сызгыра да тынып кала, сызгыра да тынып кала. Әйтерсең үз тавышына үзе таң калып тыңлап тора. Бүтән кошларның җырын кабатлап та үртәми, тавышларын онытты микәнни?

Бераз сызгырынгандай кыланды да кояшта җылынган җиреннән йоклап та китте. Сайрап туймас чак лабаса хәзер. Ул исә, башын бер якка салып, күзләрен йомып, тик калыгып утыра. Бер дә болай булмый торган иде бит.

Алтынчы көзендә сыерчык буш оясына соңгы тапкыр очып кайтты. Тын гына боегып утырды, аягындагы балдагын капшады.

— Исән бул! — дип алтынчы тапкыр саубуллаштым мин аның белән.

Яз килде. Сыерчык янә очып кайтты. Тик монысы минем балдаклы танышым түгел иде инде. Бәлки яшьрәк күршесе йә улы булгандыр. Яшь, көчле тавышлы, җитез. Йон-каурыйлары ефәктәй елкылдап тора.

Ә карт сыерчык бүтән әйләнеп кайтмады. Каурый-канатларын җилләр кайларга таратты икән аның?

## МИЛӘШ ЧЫПЧЫГЫ БЕЛӘН ЯБАЛАК

— Әйт әле миңа, ябалак, сине байгыштан ничек аерырга? — дип сорады беркөнне миләш чыпчыгы ябалактан.

— Нинди ябалак бит...

— Ничек инде нинди, гади ябалак!

— Ә-ә, андый ябалак булмый, кайсы икәнен атап әйт. Күп төрле бит без: карынкыл ябалак, соры ябалак, карчыга ябалагы, саз ябалагы, кар ябалагы, колаклы ябалак...

— Ә менә син үзең — нинди ябалак?

— Минме? Мин — озынкойрыклы соры ябалак буламын.

— Сине байгыштан ничек аерырга соң?

— Нинди байгыштан бит... Кара төстәге урман байгышын әйтәсеңме, ачык төстәге чүл байгышынмы? Әле тагын балык байгышы да бар...

— Тьфү, төн ябалагы! Бутап бетердең инде. Болай булгач, кемнең кем икәнен үзегез дә аермый торгансыздыр әле.

— Уһу-һу-һу! — дип уһылдарга гына калды ябалакка.

## САЗЛЫКТАГЫ ФЛАГЛАР

Җылы юрган астыннан бер генә дә чыгасы килми.

Тышта суык язгы төн, искә төшерсәң дә, каз тәне чыга. Ирекле баштан, әче таңнан торып, ничекләр генә каткан куртканы, салкын итекне киясе?

— Тагын кая тыкшынасың, ни җитмәгән сиңа? — дип астан гына котыртырга ашыкты «иренчәк» мин дә.— Сазлык күргәнең юкмы әллә? Аяк астында су чупырдый, баткактан итегеңне көчкә-көчкә сөйрәп аласың, ботак-сатак күзеңә керә...

Икенче яктан «тынгысыз» мин гайрәт чәчте:

— Исең киткән икән иске чикмәнгә? Баткаклык, сазламык имеш?! Беренче тапкыр мәллә? Берәр кызыктан колак каксаң нишләрсең?

— Авыз күтәреп әйтерлек нәрсә булсын инде анда? — дип җиңешче «иренчәк» мин.— Туймадыңмыни әле язның яз буе пычрак ярып йөреп? Син күрмәгән нәрсә юк бит инде. Ниләр булганы минутлап язып куелган. Өч туларга ун минутта чуллык күренә, сәгать өчтә ата көртлекләр очып килә. Биш тулып ун минутта каргалар оча, алтынчы яртыда сазлыкка акчарлаклар төшеп куна. Шуларга карап сәгатеңне тикшерсәң дә була.

— Көтмәгәндә әллә нәрсә булып куюы бар. Алай кистереп әйтмә,— дип каршы төште «тынгысыз» мин.

— Тот капчыгыңны! «Көтмәгәндә» имеш! Көтмәгәндә ул китапларда гына була,— дип һаман боргычлады «иренчәк» мин.— Тездән суда басып торып, аягың өшер, аркаң сызлар, бармакларың язылмас. Монысы инде көтмәгәндә булмас. Көт тә тор менә!

— Шулаен шулай анысы,— дип көрсенде «тынгысыз» мин.— Аркаң да сызлар, аякларың да туңар. Акчарлаклар да алтынчы яртыда килер. Киттек! Җитәр ялкауланып ятарга!

...Бусаганы атлап чыккач, караңгыга күз ияләшсен дип, туктап калдым. Менә болыт астыннан ай күренде. Аяк астын бераз шәйләрлек булгач, юлга кузгалдым.

Авыл буйлап атлыйм. Салкынча. Аяк асты пычрак, итекне көчкә сөйрәп алам. Көлтә-көлтә ай нуры тәрәзәләргә төшкән. Әйтерсең өй эчендә гөлт итеп ут яндыралар да шунда ук сүндерәләр.

Авылны чыгып сазлыкка җиттем. Хәзер инде ай нуры җирдәге күлдәвекләргә төшә. Һәммәсе «иренчәк» мин әйткәнчә: караңгысы да, салкыны да, пычрагы да...

«Тынгысыз» мин, бирешмәскә теләп, соңгы көченә

хырылдап сулый. Мине шалашка кертеп җибәрә дә борынымны яка эченә яшерә.

Өч туларга ун минут. Баш очымда чуллык күренде.

Сәгать өч. Қыска-кыска «па-па-па» дип тавыш биреп, янәшәмә ата көртлек төшеп кунды.

Өч тулып биш минут.

Шешәдән су агызгандай нәрсәдер былт-былт былкылдый. Ата көртлек гөлдери икән.

— Менә, әйттемме мин сиңа,— дип «иренчәк» мин тантана итә.

Һәм кинәт...

«Тынгысыз» мин колакка тукый:

— Мондыйны ишеткәнең юк иде бит, игътибар белән тыңла әле.

— Әкрен, шыпырт,— дип тынычландырам мин аны.— Сиңа тоелгандыр гына.

Тоелмаганын үзем дә белеп торам инде. Моңарчы ишетмәгән-белмәгән авазлар колакка чалына. Мин тыңлый-тыңлый дәфтәремә язып куйдым: «Дүртенче ярты. Қара сазлык ягыннан нindидер билгесез тавыш килә, әйтерсең куыклар шартлый». Алдан әйткәнемчә, алтынчы ун минутта карга очып үтте. Нәкъ алтынчы яртыда акчарлаклар күренде. Хәзер инде «иренчәк» мин дә бик мыскылламый башлады.

Қояшның тәүге кыйгач нурларыннан сазлыктагы су алтынга мангандай. Түмгәк башлары гына аерылып тора. Түмгәк саен дип әйтерлек ак «байраклар» җилферди. Ак нокталар бер күренәләр, бер югалалар. Гадәттә көзгедә кояш нурлары шулай уйный. Юк, болар икенче. Болар — тәкәрлекләр. Гомеремдә беренче тапкыр тәкәрлекләр биюен күрәм.

«Тынгысыз» мин «иренчәк» минне якасыннан эләктереп селки үк башлады.

— Яхшылык белән туктыйсыңмы, юкмы елавыңнан? Әйттемме мин сиңа көтмәгәндә булыр дип?

Һәр түмгәктә бер пар. Күз явын алырлык матурлар. Канатлары, аркалары яшькелт төстә, түшләре кардай ак, аяклары кызыл, иртәнге чыктан һәм кояш нурларыннан ялтырап торалар.

Тәкәрлекнең бер сыңары башын иеп ала да, томшыгы белән үләнне өзеп, уңга чөеп ыргыта. Икенче сыңары да җавап итеп башын ия һәм үләнне өзеп сулга ташлый. Алар шушы төштә оя корачак.

«У-у, ку-ку-ку! У-у, ку-ку-ку-ку!» дип егет тәкәрлек туй җырын башлый. Үзе түше белән иелеп мүккә күмелә дә җыйган канатларын тырпайтып, койрыгын өскә кайтарып, ак яулыктай болгый башлый.

Тәкәрлекләрнең көтеп алган көннәре бу. Шушы манзараны күрми калган булсам, бик кызганыч булыр иде. Бу кошларны сазлык түмгәкләрендә шулай матур бииләрдер дип башыма да китерми идем.

«Иренчәк» минне борыны белән мүккә батырам. Яңаны белми калу искене онытудан яманрак бит.

## КЫШКЫ БУРЫЧЛАР

Бер Чыпчык тирес өемендә чыркылдый-чыркылдый тырк-тырк сикеренә иде. Читән башына кунган Карга моны күреп алды да карлыккан тавышы белән кисәтү ясады:

— Нәрсәгә дип шул тикле куанасың, Чыпчык? Чырык-чырык килеп теңкәгә тиясең?

— Канатларым кымырҗый, Карга, борыным кычыта,— диде аңа Чыпчык.— Сугышасым килә, көчкә түзәм. Син каркылдап кәефемне җибәрмә инде, яме!

— Менә үзеңә бер сорау бирсәм, кәефеңнән җиләр исәр әле! — дип янады Карга.

— Һе, бик куркыттың инде соравың белән!..— диде артык исе китми генә Чыпчык.

— Куркытырмын да. Кышын чүп-чар чокырында ипи валчыклары чүпләдеңме?

— Чүпләдем, чик-чик!

— Ындырда ашлык бөртекләре җыйдыңмы?

— Җыйдым, җыйдым!

— Мәктәп янындагы кошлар ашханәсендә туендыңмы?

— Балаларга рәхмәт, туйдырдылар, чик-чик.

— Менә шул-шул! — диде үртәлеп Карга.— Хәзер шуларны ничек түләп бетермәкче буласың соң? Чырк-чырк килепме?

— Әллә мин үзем генә туенганмы? — дип каршы килде Чыпчык.— Песнәк, Тукран, Саескан, Чәүкәләр бөтенесе кыш буе ашап чыктылар бит. Кайчан карама үзең дә шунда идең...

— Син бүтәннәрне кыстырма, яме,— дип каркылдады Карга.— Башта үзең өчен җавап бир. Бурычлы икәнсең — адәм рәтле кошлар кебек кайтара да бел.

— Адәм рәтлеләре, бәлки, кайтаралардыр да. Ә менә син үзең түлисеңме соң? — диде ачуы килгән Чыпчык.

— Мин бөтенегездән алданрак түләдем инде. Басуда трактор гөрләгәнен ишетәсеңме? Мин аның артыннан буразнадан тамыр ашаучы корт-бөҗәкләрне җыеп барам. Саескан белән Чәүкә дә миңа булыша. Бүтән кошлар да бездән үрнәк алалар.

— Син инде бүтән кошлар өчен җавап бирмә,— диде Чыпчык үҗәтләнеп.— Бүтәннәр әллә кайчан онытып та бетергәннәрдер инде.

Карга да үз сүзен бирмәде:

— Ә син бар, ышанмасаң, очып-әйләнеп, тикшереп кил!

Чыпчык тикшерергә китте.

Җиләк-җимеш бакчасына очып килсә, күрә: Песнәк агачка яңа куыш ясаган.

— Котлы булсын яңа өең! — дип сәламләде аны Чыпчык.— Сөенечеңнән башың әйләнеп, бурычларың барын да оныткансыңдыр әле.

— Онытаммы соң? Бик исемдә, Чыпчыккай! — диде Песнәк.— Мине балалар кыш буе тәмле куй мае белән сыйладылар. Кунак ашы — кара каршы, көз җиткәч минем дә аларны матур алмалар белән сөендерәсем килә, шуңа агачларны корткыч-бөҗәкләрдән саклыйм.

Моңа артык бәйләнүдән файда юк дип, Чыпчык очып китте. Урманга килсә, Тукран үзенең чүкечен тукылдатып утыра. Ул Чыпчыкны күреп аптырый калды.

— Ни йомышың төште, Чыпчык? Урман кадәр урманга ук очып килгәнсең? — диде.

— Менә, кышкы әҗәтеңне кайтар дип бәйләнәләр миңа,— диде чырык-чырык килеп Чыпчык.— Ә син, Тукран, ничек итеп бурычыңны түлисең?

— Тырышам инде хәлдән килгәнчә, әҗәтле булып калмаска исәп,— диде Тукран.— Урманны агач кортларыннан, кайрыашарлардан саклыйм. Шуларны бетерәм дип корсагымны да җәлләп тормыйм. Юанаеп беттем...

— Алай икән эшләр...— дип уйга калды Чыпчык.— Уйлап җиткермәгәнмен...

Чыпчык тирес өеменә әйләнеп кайтты да Каргага әйтте:

— Сүзең хак икән, Карга! Бөтен кош-корт кышкы әҗәтләрен кайтару белән мәшгуль. Ә минем кай жи-

рем алардан ким? Кошчыкларымны озынборыннар, чебеннәр, сукыр кигәвеннәр ташып туйдыра башлыйм моннан соң. Алайса бала-чаганың үзәгенә үтәләр каннарын эчеп. Менә, миңа да җай чыкты бурычымны түләргә.

Чыпчык шулай диде дә тагын тирес өемендә чырык-чырык килеп сикеренергә тотынды. Әлегә буш вакыты бар, оясындагы йомыркалар борынламаган бит.